ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.03.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 621**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Икътисадый совет төзү турында» 2020 елның 16 мартындагы 502 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2020 елның 21 мартында видеоконференцэлемтә режимында узган республика киңәшмәсендәге Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов йөкләмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 мартындагы 620-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Икътисадый совет төзү турында» 2020 елның 16 мартындагы 502 номерлы карарын түбәндәге эчтәлекле 4 пункт белән тулыландырырга:

«4. Яңа коронавирус йогышы таралуга, нефтькә һәм доллар курсына бәяләр волатильлегенә бәйле рәвештә начарланган вәзгыятьтә Зеленодольск муниципаль районы икътисадын тотрыклы үстерүне тәэмин итү чаралары планын кушымта нигезендә расларга».

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 мартындагы 502 номерлы карарындагы «Зеленодольск муниципаль районы Икътисадый советы составы» 1 нче кушымтаның 18 абзацында Галиев Әуфар Зөфәр улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск сөт эшкәртү комбинаты» АҖ генераль директоры».

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 мартындагы 502 номерлы карарының 4 пунктын 5 пункт дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары — А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән
расланды
30.03.2020 №621

Яңа коронавирус йогышы таралуга, нефтькә һәм доллар курсына бәяләр волатильлегенә бәйле рәвештә начарланган вәзгыятьтә
Зеленодольск муниципаль районы
икътисадын тотрыклы үстерүне тәэмин итү чаралары планы

| № т/б | Чаралар атамасы | Документ төре | Срогы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Зеленодольск муниципаль районында кулланучылар бәяләренә оператив мониторинг | | | ЗМР БК кулланучылар базары бүлеге |
| 1.1. | Кулланучылар товарларына бәяләр мониторингы тәртибе һәм гамәлгә кертү турында карар кабул итү | ЗМР БК Икътисадый советына, вәзгыять начарайган очракта-Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына оператив мәгълүмат | атна саен 2020 елның 30 мартыннан башлап | |
| 1.2. | ЗМР БК каршындагы Икътисадый совет утырышында куллану товарларына бәяләрнең шактый тайпылу сәбәпләрен карау | ЗМР БК каршындагы Икътисадый совет утырышы беркетмәләре | кирәк булганда | |
| 1.3. | Сәүдә челтәрләре һәм эшкәртү предприятиеләре белән азык-төлек товарларына бәяләрне шактый арткан̈да арттыру мөмкинлегең килештерү (аерым азык-төлек продуктлары җитештерүчеләргә субсидияләр турында карар кабул итеп) | Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларының торышын тикшереп тору буенча оператив штаб тәкъдимнәре | кирәк булганда | |
| 2. | ЗМР сәүдә оешмаларында беренче кирәкле товарларның булу-булмавы буенча оператив мониторинг: | ЗМР БК икътисади советына оператив мәгълүмат | көн саен | ЗМР БК кулланучылар базары бүлеге |

| № т/б | Чаралар атамасы | Документ төре | Срогы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | азык-төлек | | | |
| | балалар товарлары | | | |
| | дару чаралары, медицина эшләнмәләре, дезинфекция чаралары һәм шәхси саклану чаралары | | | |
| 3. | Зеленодольск муниципаль районында, шул исәптән Зеленодольск моношәһәрендә, хезмәт базарындагы ситуациягә оператив мониторинг | ЗМР БК икътисади советына оператив мәгълүмат | атна саен, 2020 елның 30 мартыннан башлап | «Зеленодольск шәһәре халкын эш белән тәэмин итү үзәге»ДКУ |
| 4. | Халыкны эш белән тәэмин итүгә актив ярдәм итү чараларын тормышка ашыру | | | «Зеленодольск шәһәре халкын эш белән тәэмин итү үзәге»ДКУ |
| 4.1. | Предприятие хезмәткәрләренең эштән азат ителү куркынычын һәм аларны яңа булдырыла торган эш урыннарына урнаштыру мөмкинлеген бәяләү | норматив хокукый акт | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителгәннән соң | |
| 4.2. | Зеленодольск шәһәре мәшгульлек үзәге ресурсларыннан файдаланып, персоналны системалы-әһәмиятле оешмаларга сайлап алу һәм җәлеп итү системасын булдыру | норматив хокукый акт | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителгәннән соң | |
| 4.3. | Эре бизнес белән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары кооперациясе турында тәкъдимнәр әзерләү, шул исәптән предприятиеләрнең азат ителә торган хезмәткәрләре өчен яңа эш урыннары булдыру максатында | норматив хокукый акт | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителгәннән соң | |
| 4.4. | Эштән азат ителү куркынычы астында булган хезмәткәрләрне яңадан укытуны һәм квалификацияләрен күтәрүне оештыру | норматив хокукый акт | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителгәннән соң | |
| 5 | Авыл хуҗалыгы ярминкәләре уздыру | - | даими | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек |

| № т/б | Чаралар атамасы | Документ төре | Срогы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | | | | министрлыгының ЗМР буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе |
| 6. | Беренче чиратта кирәкле азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар китерүне гамәлгә ашыручы транспорт чаралары өчен шәһәр читендә хәрәкәт итүгә һәм йөк төяүгә-бушатуга чикләүләрне вакытлыча бетерү | ЗМР БК карары | 2020 елның 27 марты | «ЗМР төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ |
| 7. | Бюджет чыгымнарын оптимальләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хисабы | 2020 елның 1 мае | «ЗМР Финанс-бюджет палатасы » МУ |
| 8. | Территориаль иҗтимагый үзидарәләр, яшьләр оешмалары, яшүсмерләр клублары, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия белән берлектә карантинлы режимны бозган балаларның, шул исәптән өстәмә каникуллар вакытында да, контролен һәм мәшгульлеген тәэмин итү | норматив хокукый акт | 2020 елның<br>30 мартыннан | ЗМР БК мәгариф идарәсе |

ЗМР – Зеленодольск муниципаль районы
ИК-Башкарма комитет